**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Лельвиж авыл җирлеге Башлыгы**
**карары**

**2020 елның 13 ноябре №3**

**«Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

*1.* 2020 елның 25 ноябренә 08 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын*** үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

*2.* 2020 елның 25 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын*** үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

*3.* 2020 елның 25 ноябренә 17 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылында ***үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын*** үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Лельвиж авылы, Мәктәп урамы, 2 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында үткәрергә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), Бөек Ватан сугышында катнашучылар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең Лельвиж авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Лельвиж авылының Май, Яр буе урамнарындагы юлларга вак таш җәю; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Лельвиж авылының Совет урамында вак таш җәеп юллардагы чокырларны төзекләндерү (ямочный ремонт) (вак таш сатып алу, ташу, җәю), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Лельвиж авылында янгын гидрантлары, янгын рукавлары, стволлар, переходниклар һәм колонкалар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Лельвиж авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу), килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Лельвиж авылында су белән тәэмин итү челтәрен алмаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- бетон нигезле агач урналар сатып алу һәм урнаштыру, сәхнә түбәсен ябу, проект-смета документларын эшләү;
- Лельвиж авылы чишмәсен төзекләндерү (бураны буяу һәм чишмәнең түбәсен алыштыру), килешү буенча эшләр өчен түләү;
- Лельвиж авылында урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган аншлаглар сатып алу һәм урнаштыру;
- Лельвиж авылында урамнарны яктырту өчен светодиод лампалар сатып алу;
- Лельвиж авылына һәм Лельвиж авылы мәдәният йортына тышкы видеокүзәтү камералары алу (сатып алу) һәм урнаштыру (килешү буенча түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

6. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Лельвиж авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лельвиж авыл җирлеге башлыгы Э. Ю. Игнатьева